**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САВАЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Центральная, д.11, с. Савалеево,
Заинский район, 423537

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СӘВӘЛӘЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

Үзәк урамы, 11 нче йорт, Сәвәләй авылы, Зәй
районы, 423537

Телефон / факс 62-3-47. Электронный адрес: Sav.Zai@tatar.ru,
сайт: http://zainsk.tatarstan.ru/rus/savaleevskoe.htm

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.03.2020 ел**

**КАРАР**
**№03**

**«Зәй муниципаль районы Сәвәләй
авыл җирлеге территорияләрен
санитар чистарту буенча икеайлык
үткәрү турында»**

Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге территориясен тиешле санитар тәртипкә китерү, язгы-көзге чорда торак пунктлар территорияләренең экологик торышын яхшырту, урамнарны, ишегалды территорияләрен төзекләндерү, аларны халыкның санитар-эпидемиологик һәм экологик куркынычсызлыгына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Уставының 42 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге башкарма комитеты

**карар бирә:**

1.Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге территорияләрен чистарту буенча түбәндәге срокларда санитар-экологик икеайлыклар игълан итәргә (алга таба - икеайлык):

- 2020 елның 01 апреленнән 31 маена кадәр;
- 2020 елның 01 сентябреннән 31 октябренә кадәр.

Икеайлык чорында бөтен җирдә җыештыру эшләре үткәрү өчен бердәм санитар көннәр итеп һәр атнаның чәршәмбе, җомга көннәрен билгеләргә.

2. Икеайлыкны үткәрү буенча эшче төркем составын 1 нче кушымта нигезендә расларга (килешү буенча).

3. Икеайлык үткәрү чорында Сәвәләй авыл җирлеге оешмаларына һәм учреждениеләренә территорияләрне беркетүне 2 нче кушымта нигезендә расларга (килешү буенча).

4. Икеайлык үткәрү буенча төп чараларны үткәрү планын 3 нче кушымта нигезендә расларга.

5. 2020 елның 25 апрелен һәм 26 сентябрен авыл җирлеге территорияләрен санитар чистарту буенча гомуми шимбә өмәсе үткәрү көннәре итеп билгеләргә.

6. Сәвәләй авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.М. Соколовага икеайлык үткәрү буенча эшләрнең барышы турында Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының ТКХ бүлегенә хәбәр итәргә.

7. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

7.1. Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә урнашкан барлык милек рәвешләрендәге оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләренә әлеге карар белән билгеләнгән территорияләрне санитар чистартуда, төзекләндерүдә, яшелләндерүдә катнашырга, кирәкле санда кешеләр һәм транспорт җәлеп итәргә.

7.2. Шәхси ярдәмче хуҗалыклар хуҗаларына ишегалды территорияләрен санитар чистартуны, торак йортларның фасадларын ремонтлауны, территорияләрне яшелләндерүне оештырырга.

8. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Сәвәләй авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **П.С.Уразайкин**

Сәвәләй авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесенең
2020 елның 17 мартындагы
03 номерлы карарына
1 нче кушымта

**2020 елда Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге территорияләрен чистарту буенча икеайлыклар әзерләү һәм уздыру буенча эшче төркем составы**

| | |
|---|---|
| Уразайкин П.С. | Сәвәләй авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы |
| Соколова Л.М. | Сәвәләй авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Бутяева О.Г. | Сәвәләй мәдәният йорты директоры (килешү буенча) |
| Иванов В.Н. | Сәвәләй мәктәбе директоры (килешү буенча) |
| Москова Е.Г. | «Ромашка» балалар бакчасы мөдире (килешү буенча) |
| Тюлиганова Р.В. | Сәвәләй ОПС мөдире (килешү буенча) |
| Камалиев Ф.Т. | Сәвәләй МПК җитәкчесе (үсемлекчелек) (килешү буенча) |
| Хәйрулин Р.А. | Сәвәләй МПК җитәкчесе (терлекчелек) (килешү буенча) |
| Рябова Н.В. | Сәвәләй китапханәсе китапханәчесе (килешү буенча) |
| Агапова Р.К. | Сәвәләй амбулаториясе санитаркасы (килешү буенча) |
| Кузнецова Т.А. | Кара-Елга ФАП шәфкать туташы (килешү буенча) |

Сәвәләй авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесенең
2020 елның 17 мартындагы
03 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Зәй муниципаль районы территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлыклар уздыру чорына Сәвәләй авыл җирлеге оешмаларында һәм учреждениеләрендә территорияләрне беркетү**
**(килешү буенча)**

| № п/п | Учреждение, оешма | Беркетелгән участок | Контроль |
|---|---|---|---|
| 1. | Башкарма комитет | Башкарма комитет (янәшәдәге территория)<br>Кара Елга паркы - коры үлән, чүп-чар җыю.<br>Кара Елга чишмәсе территориясе - коры үлән, чүп-чар җыю.<br>Кара Елга зираты территориясе - коры үлән, чүп-чар җыю.<br>Иске Маврин авылына юл - чүп-чар җыю. | Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Уразайкин П.С. |
| 2. | Сәвәләй авыл мәдәният йорты | Мәдәният йорты (янәшәсендәге территория).<br>Кара Елга паркы - коры үлән, чүп-чар җыю.<br>Кара Елга чишмәсе территориясе - коры үлән, чүп-чар җыю.<br>Кара Елга зираты территориясе - коры үлән, чүп-чар җыю. | Директор Бутяева О.Г. |
| 3. | Сәвәләй мәктәбе | Мәктәп (янәшәдәге территория).<br>Авылга керү өлеше, Яшел урамындагы 13 нче йортка кадәр - чүп-чар җыештыру, агач агарту.<br>Сәвәләй паркы, Бөек Ватан сугышы һәйкәле - чүп-чар җыю, буяу.<br>Сәвәләй зираты территориясе - чүп-чарны төяп чыгару | Директор Иванов В.Н. |
| 4. | «Ромашка» балалар бакчасы | Балалар бакчасы (янәшәдәге территория).<br>Сәвәләй зираты территориясе - чүп-чар, коры үлән җыю.<br>Кара-Елгага керү юлы – чүп-чар җыю | Мөдир Москова Е.Г. |
| 5. | Сәвәләй ОПС | ОПС (янәшәдәге территория)<br>Ленин һәйкәле янындагы территория - чүп-чар һәм коры үлән, яфракларны җыештыру.<br>Юл территориясе, Яшел урам буенча юл кырыйлары, Үзәк урамы борылышыннан 13нче йортка кадәр-чүп-чар җыештыру, агачларны агарту. | Мөдир Тюлиганова Р.В. |
| 6. | ПК Сәвәләй (үсемл.) | МТП (янәшәдәге территория)<br>Зәй-Әлмәт трассасы буе (уң як) - чүп-чар | Җитәкче Камалиев Ф.Т. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | жыю. | |
| 7. | МПК Сәвәләй (терл.) | МТФ (янәшәдәге территория)<br>Зәй-Әлмәт трассасы буе (сул як) – чүп-чар жыю, агачларны агарту. | Җитәкче<br>Хәйрулин Р.А. |
| 8. | Сәвәләй китапханәсе | Китапханә (янәшәдәге территория)<br>Парковкадан калиткага кадәр (Яшел ур.) - чүп-чар, коры үләнне жыештыру. | Китапханәче<br>Рябова Н.В. |
| 9. | Сәвәләй амбулаториясе | Амбулатория (янәшәдәге территория)<br>Балалар мәйданчыгы элементларын буяу. | Санитарка<br>Агапова Р.К. |
| 10. | Халыкка соц. хезмәт күрсәтү үзәге | Балалар мәйданчыгы элементларын буяу. | Соц. хезмәткәр<br>Хөсәенова И.В. |
| 11. | Кара-Елга ФАП | ФАП (янәшәдәге территория)<br>Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәл яны территориясе. | Шәфкать туташы<br>Кузнецова Т.А. |

Сәвәләй авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесенең
2020 елның 17 мартындагы
03 номерлы карарына
3 нче кушымта

**2020 елда Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге территориясен чистарту буенча санитар-экологик икеайлыклар уздыру чорына төп чаралар планы**

| № п/п | Чараларның исеме | Башкару сроклары | Башкару өчен җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Территорияләрне төзекләндерү һәм санитар чистарту буенча 2 айлык үткәрү. | 01.04-31.05<br>01.09-31.10 | Башкарма комитет<br>Сәвәләй урта мәктәбе<br>"Ромашка" б/б<br>Сәвәләй мәдәният йорты<br>Сәвәләй китапханәсе<br>Сәвәләй ОПС<br>Сәвәләй амбулаториясе.<br>ПК Сәвәләй (үсемл),<br>Сәвәләй МПК (терл.)<br>Кара Елга ФАПы.<br>ИП<br>җирлек халкы |
| 2 | Сәвәләй авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм санитар чистарту буенча гомумрайон өмәсе | 21 апрель,<br>26 сентябрь | Башкарма комитет<br>Сәвәләй урта мәктәбе<br>"Ромашка" б/б<br>Сәвәләй мәдәният йорты<br>Сәвәләй китапханәсе<br>Сәвәләй ОПС<br>Сәвәләй амбулаториясе.<br>ПК Сәвәләй (үсемл),<br>Сәвәләй МПК (терл.)<br>Кара Елга ФАПы.<br>ИП<br>җирлек халкы |
| 3 | Авыл җирлегенә кергән торак пунктлардагы урамнарны, йорт яны һәм юл буе территорияләрен, ял итү урыннарын, җитештерү мәйданчыкларын көнкүреш чүп-чарыннан чистарту. Санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, рекреацион зоналарны чистарту. | 01.04-31.05<br>01.09-31.10 | Башкарма комитет<br>Сәвәләй урта мәктәбе<br>"Ромашка" б/б<br>Сәвәләй мәдәният йорты<br>Сәвәләй китапханәсе<br>Сәвәләй ОПС<br>Сәвәләй амбулаториясе.<br>ПК Сәвәләй (үсемл),<br>Сәвәләй МПК (терл.)<br>Кара Елга ФАПы.<br>ИП<br>җирлек халкы |
| 4 | Икеайлык чорында чүп-чарны чыгару | 01.04-31.05<br>01.09-31.10 | Башкарма комитет<br>Хезмәт күрсәтүче оешмалар |
| 5 | Газоннарны, чәчәк түтәлләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү эшләре, клумбалар әзерләү, үсентеләр, агачлар һәм чәчәк | Апрель-май | Башкарма комитет<br>Сәвәләй урта мәктәбе<br>"Ромашка" б/б<br>Сәвәләй мәдәният йорты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | үсентеләре утырту, агач кәүсәләрен агарту | | Сәвәләй китапханәсе<br>Сәвәләй ОПС<br>Сәвәләй амбулаториясе.<br>ПК Сәвәләй (үсемл),<br>Сәвәләй МПК (терл.)<br>Кара Елга ФАПы.<br>ИП<br>җирлек халкы |
| 6 | Мәдәни-көнкүреш һәм җәмәгать биналарын һәм корылмаларын, кече архитектура формаларын тышкы яктан төзекләндерү, биналарның фасадларын ремонтлау буенча эшләр башкару | Апрель-октябрь | Башкарма комитет<br>Сәвәләй урта мәктәбе<br>"Ромашка" б/б<br>Сәвәләй мәдәният йорты<br>Сәвәләй китапханәсе<br>Сәвәләй ОПС<br>Сәвәләй амбулаториясе.<br>ПК Сәвәләй (үсемл),<br>Сәвәләй МПК (терл.)<br>Кара Елга ФАПы.<br>ИП |
| 7 | Зиратларны ремонтлау һәм контейнерлар урнаштыру | Апрель-май | Башкарма комитет |
| 8 | Торак зонада төзекләндерү:<br>- ишегалды һәм якын-тирә территорияләрне санитар чистарту;<br>-коймалар, бордюрлар урнаштыру;<br>- торак йортларның фасадларын ремонтлау. | 01.04-31.05<br>01.09-31.10 | Җирлек халкы |
| 9 | Спорт, балалар мәйданчыкларын һәм корылмаларын ремонтлау, буяу һәм тәртипкә китерү. | Май | Башкарма комитет<br>Мәктәп<br>Балалар бакчасы |
| 10 | Зиратларны һәм истәлекле урыннарны төзекләндерү буенча эшләр үткәрү. Хәрбиләр каберлекләрен, һәйкәлләрне, обелискларны торгызу һәм тәртипкә китерү эшләренә аерым игътибар бирү | Апрель-май, сентябрь-октябрь | Башкарма комитет<br>Җирлек халкы,<br>оешмалар ("Хәтер атнасы" акциясе кысаларында) |
| 11 | Сулыкларның яр линияләрен чистарту буенча эшләр башкару | Апрель-май | Башкарма комитет<br>Җирлек халкы,<br>оешмалар ("Чиста ярлар" акциясе кысаларында) |
| 12 | Агач утырту буенча эшләр башкару | Апрель, октябрь | Башкарма комитет<br>Җирлек халкы,<br>оешмалар ("Агач утырту көне" акциясе кысаларында) |
| 13 | Һәйкәлләрне, хәрби дан мемориалларын, истәлекле табличкаларны ремонтлау (реставрацияләү) һ. б. | Апрель-май | Башкарма комитет |
| 14 | Якын-тирә территорияләрдә, | Май-август. | Башкарма комитет |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | урам һәм юл буйларында үлән чабу. | | Сәвәләй урта мәктәбе<br>"Ромашка" б/б<br>Сәвәләй мәдәният йорты<br>Сәвәләй китапханәсе<br>Сәвәләй ОПС<br>Сәвәләй амбулаториясе.<br>ПК Сәвәләй (үсемл),<br>Сәвәләй МПК (терл.)<br>Кара Елга ФАПы.<br>ИП<br>җирлек халкы |
| 15 | Юллардагы чокырларны ямау, авыл җирлеге урамнарын грейдерлау, юл буйларын чистарту | Апрель-октябрь | Башкарма комитет<br>Зәй УАДы. |
| 16 | Янәшәдәге территорияләрне һәм беркетелгән участокны яфрактан һәм корыган үләннән чистарту | Сентябрь-октябрь | Башкарма комитет<br>Сәвәләй урта мәктәбе<br>"Ромашка" б/б<br>Сәвәләй мәдәният йорты<br>Сәвәләй китапханәсе<br>Сәвәләй ОПС<br>Сәвәләй амбулаториясе.<br>ПК Сәвәләй (үсемл),<br>Сәвәләй МПК (терл.)<br>Кара Елга ФАПы.<br>ИП<br>җирлек халкы |
| 17 | Инженерлык челтәрләрен ремонтлау эшләрен башкарганнан соң урамнарны төзекләндерү | Даими | Оешмалар,<br>төзелеш оешмалары, индивидуаль төзүчеләр. |

Сәвәләй авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесенең
2020 елның 17 мартындагы
03 номерлы карарына кушымта

Танышу кәгазе.

| ФИА | Танышу турында билге | |
|---|---|---|
| | Дата | Имза |
| Соколова Л.М. | | |
| Бутяева О.Г. | | |
| Иванов В.Н. | | |
| Москова Е.Г. | | |
| Тюлиганова Р.В. | | |
| Камалиев Ф.Т. | | |
| Хәйрулин Р.А. | | |
| Рябова Н.В. | | |
| Агапова Р.К. | | |
| Кузнецова Т.А. | | |